РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«31» мая 2023г.

№ 87

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 24 ноябрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының 2023 елның 3 маендагы 408-исх. номерлы, МКУ «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»нең 2023 елның 12 маендагы 159 номерлы хатларын карап, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансл‌ы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, «2023 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2022 елның 1 сентябрендәге 934 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар тукланунының уртача бәясен оештыру һәм аларга түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 елның 3 октябрендәге 1065 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Бшакарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 24 ноябрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» карарына (08.02.2016 № 41, 29.01.2017 № 34, от 20.06.2017 № 328, 29.12.2018 № 879, 16.11.2020 № 498, 31.12.2020 № 620, 15.02.2021 № 55, 19.03.2021 № 124, 29.12.2021 № 325, 10.10.2022 № 197, 13.12.2022 № 266, 20.01.2023 № 4 карарлар редакциясендә) (алга таба текст буенча - 559 номерлы карар) түбәндәге эчтәлектәге 1.2.6 пунктча белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«1.2.6. 2023 елның 1 сентябреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр укучы инвалид балаларны (аларның сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган бала статусына ия булуларына карамастан) һәр уку көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия һәм ата-ана түләвеннән торган бушлай кайнар туклану белән тәэмин

итүне оештырырга. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләвен җирле бюджет акчалары исәбеннән түләргә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин